ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ УРЫССУ БИСТӘСЕ СОВЕТЫ

**КАРАРЫ**

«_03_» _04 _2026 ел Урыссу штб № _6__

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында»гы 25.12.2008 № 273-ФЗ Федераль законнар, "Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе Президентының кайбер актларын үзгәртү һәм үз көчләрен югалткан дип тану турында»гы 31.12.2025 № 1009 Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе Советы карар бирде:

1. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе Советының 08.09.2017 № 11 карары «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрне урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастыру тәртибен раслау турында»;

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе Советының 28.06.2021 № 10 карары «Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында белешмәләр бирү турында һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе Советының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт

(Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгән вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районының "Урыссу
шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль
берәмлеге Советы Рәисе,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районының
шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе
Башлыгы А.Ә. Шәфигуллин